Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты
карары

13 май 2020 ел № 633

«Олимпия күтәрелешендәге скважиналарны төзекләндерү» объекты өчен территорияне планлаштыру проектын һәм ызанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планировка структурасы элементларын бүлеп бирү максатларында, «Теплогазпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять мөрәҗәгате нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районының Баграж-Никольский, Яңа Троицкий авыл җирлекләре территориясе буйлап уза торган «Олимпия күтәрелешендәге скважиналарны төзекләндерү» объекты өчен «Теплогазпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үз акчалары исәбеннән объектны планлаштыру проектын әзерләүгә һәм ызанлау проектын әзерләүгә керешергә тәкъдим итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р.Р.) территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту тәртибе, сроклары турында әлеге тәкъдимне кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д. В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Әлмәт муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның
«13» май  № 633 карарына
1 нче кушымта

«Олимпия күтәрелешендәге скважиналарны төзекләндерү» объекты өчен
территория чикләре




Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
төзелеш буенча урынбасары                                                                  Д.В. Косарев